| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**15.02.2023** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№360** |

Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 27 мартындагы 04-03-31 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районының 2029 елга кадәр җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында»190-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмаларының гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләүгә һәм раслауга таләпләр турында» 154 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 27 мартындагы 04-03-31 номерлы карары белән расланган, «2029 елга кадәр Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

- «Җылылык белән тәэмин итү максатларында җылылык энергиясен перспективалы куллану» 1 бүлекнең 1.5 пунктын түбәндәге текст белән тулыландырырга:

- Шәһәрнең торак фонды һәм инфраструктурасы объектлары буенча, шулай ук кулланучыларда җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары урнаштыру белән бәйле җылылык энергиясенең фаразланган файдалы җибәрелүе түбәндә бирелгән дәрәҗәдә кө тәлә:

- 2024 ел - 423315,0 Гкал;
- 2025 ел - 423315,0 Гкал;
- 2026 ел - 423315,0 Гкал;
- 2027 ел - 423315,0 Гкал;
- 2028 ел - 423315,0 Гкал.

-«Төзелешкә, реконструкциягә һәм техник җиһазлауга инвестицияләрне нигезләү» 9 бүлекнең 9.1 пунктын түбәндәге текст белән тулыландырырга:

- Фрунзе урамы буенча ТК-2 дән алып ТК-8 кадәр озынлыгы 150 метр 2Ф300, озынлыгы 220 метр 2Ду250, озынлыгы 374 метр Ф160/110 булган 19 кв.котельнаяның магистраль җылылык челтәре һәм ГВС челтәрен реконструкцияләү.

- Төзүчеләр урамы буенча ТК-18/1дән ТК-19га кадәр 90 метр озынлыкта 2Ф500 булган «А» микрорайоны котельнаяның магистраль җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Башкала урамы буенча ТК-27дән ТК-28гә кадәр «А» микрорайоны котельнаясының 180 метр озынлыкта 2Ф300 булган магистраль җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Башкала урамы буенча ТК-28дән ТК-31гә кадәр 399 метр озынлыкта 2Ф250 булган «А» микрорайоны котельнаяның магистраль җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Тукай урамы буенча ТК-1/1 дән алып ТК-33 кә кадәр 215 метр озынлыкта 2Ф300 булган 1-7 кв.котельнаяның магистраль җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Засорин урамы буенча 29-30 кв. котельнаясыннан ТК ДОСААФ кадәр 330 метр озынлыкта 2Ф200 булган 29-30 кв. котельнаясының магистраль җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Королев урамы буенча ТК-9дан ТК-7гә кадәр 410 метр озынлыкта 2Ф300 булган «А» микрорайоны котельнаясының магистраль җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Б.Урманче урамы буенча ТК-7/1дән ТК-23кә кадәр 310 метр озынлыкта 2Ф300 булган «А» микрорайоны котельнаясының магистраль җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Жуков урамы буенча ТК-17дән КРТП №4 кадәр 230 метр озынлыкта 2Ф250 булган«А» микрорайоны котельнаясының магистраль җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Паратск урамы буенча ТК-8дән ТК-11гә кадәр 300 метр озынлыкта 2Ф500мм булган 1-7 кв.котельнаясының җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Паратск урамы буенча ТК-11дән ТК-8/1гә кадәр 124 метр озынлыкта Ф140/110,156 метр озынлыкта Ф125/90 булган кв.1-7 котельнаясының ГВС җылылык челтәрен реконструкцияләү.

- Гоголь урамы 43 һәм Кояшлы 81 адресы буенча урнашкан торак йортларга карата озынлыгы 200 метр Ф110/75, озынлыгы 187 метр Ф75/50, озынлыгы 170 метр Ф40/32 булган ГВС челтәрен реконструкцияләү.

Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы Р.Н. Чибриковага, әлеге карар кабул ителгән көннән 15 көн эчендә, аны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин